**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ИЛДЕРӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

**КАРАР**

№ 1 11.01.2016 ел

**Референдум үткәрү инициативасы турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьяларына, Татарстан Республикасы Законының 18 статьясына ярашлы 24.04.2004 № 23-ТРЗ «Җирле референдум турында», Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Иске Илдерәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, карар бирәм:

1.Җирле референдум үткәрү инициативасы:

«Сез 2016 елда 18 яшькә җиткән, яшәү урыны җирлек чикләрендә урнашкан, шулай ук теркәлмәгән, әмма җирле референдумда катнашуларына һәм алар каршында белдергән мөнәсәбәтләренә карамастан, Иске Илдерәк авыл җирлеге территориясендә яшәүче яки милеккә ия булган һәр кешедән 300 сум күләмендә үзара салым акчаларын еллык бер тапкыр түләүне кертүгә ризамы 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм студентлардан кала тавыш бирү, көндезге уку формасы буенча укучылар алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтәләр:

1. Ритуаль хезмәтләр оештыру һәм җирләү урыннарын тоту.

- Иске Илдерәк һәм Чуваш Енорускино торак пунктларында зиратларны төзекләндерү өчен төзелеш материаллары сатып алу.

2. Торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге.

- вак таш белән капланган юлларны ремонтлау, шул исәптән:

Иске Илдерәк авылында: Совет урамы; Гагарин урамы; Яшьләр урамы;

Яңа Илдерәк авылында: Үзәк урам;

Чуваш Енорускино авылында: Көнчыгыш урамы; Бакча урамы;

Тарханка авылында: Көнчыгыш урамы;

Иляшкино авылында: Төньяк урамы;

3. Торак пунктта яшәүчеләрнең күпләп ял итү өчен шартлар тудыру һәм халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру, шул исәптән гражданнарның гомуми файдалanudагы су объектларына һәм аларның яр буйларына иректе керүен тәэмин итү;

Чуваш Енорускино авылындагы чишмәне ремонтлау.

ӘЙЕ ЮК

2.Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://aksubaevo.tatar.ru Аксубай муниципаль районы Иске Илдерәк авыл җирлегенең мәгълүмати стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Иске Илдерәк авыл җирлеге
Башлыгы : В.К. Альметкин